ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ИСЛӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ КАРАРЫ

от 14.05.2020 №3

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 29 апрелендәге 15 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгы карарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислэй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында”гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында», Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислэй авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Ислэй авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәне раслау турында"гы 2016 елның 29 апрелендәге 15 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы "Ислэй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар, шулай ук “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Ислэй авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында”гы белешмәләр тапшыру турында түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктта «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында язып кую, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://chistopol.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Исләй
авыл җирлеге башлыгы В.П. Чернышев